DOI: 10.26907/2311-2042-2022-19-2-189-194

# REVIEW OF THE "EXPLANATORY DICTIONARY OF THE TATAR LANGUAGE" (2015-2021)

**Alfiya Shavketovna Yusupova,**
Kazan Federal University,
18 Kremlyovskaya Str., Kazan, 420008, Russian Federation,
alyusupova@yandex.ru.

This paper reviews the six-volume explanatory dictionary of the Tatar language ("Tatar telenen anlatmaly suzlege"; 2015–2021). Continuing the best traditions of Tatar and Russian lexicography, a team of scientists from the Institute of Language, Literature and Art named after G. Ibragimov, the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, compiled a new fundamental explanatory dictionary of the Tatar language. The dictionary includes current vocabulary and phraseological units of the modern Tatar literary language, terms and names from various fields of science and their interpretations. Neologisms are also found here, those formed with the help of the word-formation means of the Tatar language, as well as historicisms and borrowed words, actively used in the general literary language. The dictionary contains about 70 thousand words and 10 thousand phraseological units.

**Key words**: lexicography, Tatar language dictionaries, vocabulary, terminology, lexicology, explanatory dictionary

The work reviews the "Explanatory Dictionary of the Tatar Language", compiled by the scientists of the Lexicography Department of the G. Ibragimov Institute of Language, Literature and Art, Tatarstan Academy of Sciences. This six-volume fundamental work differs from previous explanatory dictionaries in its volume, content, completeness, detail and richness of illustrative material. The six-volume dictionary, which explains 70,000 words and 10,000 phraseological units, is a very relevant and significant work, accurately and fully presenting the vocabulary of the modern Tatar language.

Published after the three-volume "Explanatory Dictionary of the Tatar language" (1977-1981), this much-needed academic dictionary takes into account the changing vocabulary, the emergence of new types of units, the enrichment of existing lexemes with new meanings or shades of meaning, the coining of new words, the borrowing of new words, and reflects all the changes in the language, including new lexical units, giving new definitions in accordance with modern requirements.

The staff of the Lexicography Department of the G. Ibragimov Institute of Language, Literature and Art began the compilation of the dictionary in 2002 under the guidance of Professor F. A. Ganiev and following his instructions. At that time, the dictionary was planned to be published in only four volumes; in the course of work, its volume increased significantly. A large number of authors participated in the compilation of individual volumes of the dictionary. The main authors who participated in the creation of all volumes were F. I. Tagirova, I. I. Sabitova, F. F. Gaffarova, G. G. Saberova, E. I. Safina and O. N. Galimova.

Scientific editors of the dictionary were F. F. Gaffarova (volumes I-III), G. G. Saberova (volumes I-II), F. I. Tagirova (volumes I-VI), R. T. Safarov (volumes III-VI). A. A. Timerkhanov was the Project Manager of Volumes I-V, and R. T. Safarov was responsible for volume VI.

The first volume of the dictionary includes "Introduction", "List of the used literature and lexicographic sources", "Information about other sources used in the dictionary", "Guide for users of the dictionary" and "List of labels and symbols". Detailed, clearly written information helps to conveniently use all six volumes of the dictionary.

First of all, the work provides definitions of words expressing the basic concepts found in textbooks of secondary schools and universities, the main terms presented in vocabulary minimums and terminological dictionaries, words related to religion, folk beliefs, mythology, rituals, various rites, social and political topics that appear in newspapers and magazines, terms, obsolete words that have come back into use, obsolete words that reflect historical facts and past lifestyles, dialect words that are often found in literature and enrich the literary language. The explanatory dictionary does not include professional words, used only in certain areas of science and technology, local colloquial words that do not enrich the literary

language, slang words, abbreviations consisting of letters and sounds, and proper names.

Words belonging to all parts of speech are taken as a vocabulary unit. When commenting on groups of words, the compilers tried to follow a certain system. For example, adverbs are interpreted in their own way, numerals in a different way; however, the sequence in their interpretation is preserved. Words, formed by means of conversion, and their meanings are listed in the main entry of the dictionary.

The vocabulary includes not only root words, but also various types of artificial words. For example: words formed by addition (ashnachelek, ahanlelek, aylanesh) (affinity, harmony, turnover); compound words (voltmeter, yanbash, bashkisar) (voltmeter, buttock, cutthroat); abbreviated compound words (parovoz, rabfak) (steam locomotive, rabfak); paired words (ayak-kul, ozek-totek, kiem-salym) (leg-hand, intermittent, clothing); compound words (kiek kaz yuly, bala itak) (Milky Way, dress frills), etc. The first or second parts of compound words and especially productive suffixes are given in the dictionary as separate entries (for example, air-, auto-, agro-, -ara, bio-, neo-, etc.).

The result of many years of serious team work, this dictionary was created based on the achievements of all the previously published explanatory dictionaries. Considering an agglutinative-analytical nature of our language, the dictionary pays due attention to compound nouns and compound verbs. The meanings and shades of the meanings of lexemes are explained in great detail with examples from fiction or periodicals. Stylistic and grammatical characteristics of lexemes are given in accordance with the requirements of modern lexicographic science.

In the dictionary, headwords are arranged in alphabetical order with symbols and labels following the headword to describe its part of speech, source language, and stylistic features. Together with the relevant material (definitions, examples, phraseological units) they form a dictionary entry. There are articles with only one explanation and articles with 20-30 explanations. For example, a word with one explanation:

**KASHBAU** *n. ethn.* A women's headdress with a front part decorated with ribbons or inserts of pearls, coins and precious stones. *A green water lily on a blue lake, I'll take off the kashbau from my hair.* M. Jalil. *Kausaria Fatihovna was presented with a most beautiful ring that glistened like a golden kashbau worn by princesses.* T. Galiullin.

In a dictionary entry containing several definitions, the definitions are listed one after the other each beginning with a new line:

**DISTA (TEN)** *n. farsi.* 1) Ten units; a unit of measure consisting of ten units. *There were about a dozen letters from parents.* M. Gafuri.

2) *spoken* Ten years old, life equal to ten years. *My knowledge is also not very good, and my age is approaching the upper part of the sixty-year-old.* G. Bashirov.

3) The name of the penultimate digit in a multi-digit number.

As the words possess not only meanings and shades of meanings that are especially actively used, but also phraseological units and set phrases that include this word, they are followed by phraseological units starting with this word, and are given at the beginning of a new line. For example, the word *mogez* (horn) has nine meanings. Thus, the dictionary entry consists of nine definitions and illustrative material corresponding to all of them. They are followed by five phraseological units associated with the word *mogez* (horn). And the even more frequent word *kuz* (eye) has 22 meanings explained and 449 phraseological units, starting with the word *kuz* (eye). These explanations, examples and set phrases, which help understand the richness of our language, the views and beliefs of our people, provide the most complete information about the word *kuz* (eye).

Unlike other dictionaries, the new dictionary focuses on verbs. Dictionary entries, describing verbs, are distinguished by their breadth and completeness. It is striking that the verbs, used in the Tatar language, are incredibly versatile and can be used in various situations. For example, the dictionary provides 17 meanings of the verb *karau* (to look). In addition, the dictionary has a list of compound verbs, such as *karap alu* (to have a look), *karap beteru* (to finish looking), *karap kuyu* (to look), *karap toru* (to stare), *karap utu* (to look through), *karap chygu* (to look around), *kary bashlau* (to start looking), *kary biru* (to keep looking), each case is explained and examples from literary works are given. There are 54 meanings of the verb *alu* (to take) (plus the functions of its meanings as the noun, copula, auxiliary verb), 64 meanings of the verb *toshu* (to descend) (plus 6 more meanings in the function of the auxiliary verb), 12 compound verbs: *tosha bashlau* (begin to descend); *tosha yazu* (almost to go down); *toshep*

*kitu* (to go down, fall suddenly, unexpectedly). The polysemy of verbs and their active use in various forms shows how rich our language and speech are.

The six volumes contain many new words not recorded in previous dictionaries. Among them are words coined in the Tatar language on our own territory, as well as words borrowed from foreign languages. For example, **KABULHANA** *n. arab.-far. neol.* Reception for visitors in official places; **KALAMHAK** *n. neol.* Fee, money for authorship; **KUKTERAR** *adj. neol.* Too high, layered; **UZALLY** *adj. neol.* 1. Independent. 2. Adv. independently; **HAYPLY** *adj. neol.* Made popular by aggressive advertising, especially famous; former in vernacular; **CHALLENGE** *n. English neol.* Internet video genre in which the blogger encourages others to imitate their work or behavior, etc.

Another important aspect of the dictionary is commenting on dialectal, obsolete, colloquial words, etc., which are found in the literary language. By presenting all the semantic shades of units that reflect the vitality and national characteristics of the Tatar people, the dictionary expands the scope of this lexical layer (**YASHLAVEK** *n. dial.* Young grass. *He remembered that even next to Vagapov Mustafa's behavior was relaxed, and the "brother"kept teasing him ('браток'ның әледән-әле аның салпы ягына* ***яшьләвек*** *кыстыруы исенә төште).* T. Galiullin. *Put the mowed young grass into his cart (Арбасына* ***яшьләвек*** *чабып салган).* A square; **KATKY** *n. dial* A device attached to the back of the sled for transporting long logs; **LAPSHYK** *adj. dial* Flaccid muscles and flesh on the body, thinned, lost their density. *If a fat horse overeats, it will be lethargic (**lapshyk**).* Proverb. *The woman's face was lethargic (**lapshyk**) and her body was very full.* Sh. Kamal).

The spelling of words is given according to existing traditional rules. The stress is indication based on the same principles. Accent marks in compound and paired words help students of the Tatar language to read these words correctly *( at lau-katlau, yarým-yorty, ký urlau, h i nak zhomla, kyrlý-myrly)*. In the dictionary there are cases of stress, which does not fall on the last syllable of the word *(iptashlə́rcha, irenmicha, ýarusly, etc.)*. The dictionary is designed to be user friendly and prevent errors not only in spelling, but also in pronunciation.

It should be noted that the six-volume dictionary is distinguished by rich and informative content due to its lexical material and explanations. This academic dictionary, containing the complete vocabulary of the Tatar language, will serve as a useful practical guide for specialists in various sciences, translators, radio and television workers, print workers, teachers and in general, for a wide range of readers, being a useful source in the comprehensive study of Tatar as a state language.

---

# «ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ АҢЛАТМАЛЫ СҮЗЛЕГЕ»НӘ (2015–2021) БӘЯЛӘМӘ

**Әлфия Шәүкәт кызы Юсупова,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
alyusupova@yandex.ru.

Рецензиядә татар теленең алты томлык аңлатмалы сүзлегенә бәя бирелә («Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»; 2015–2021). Татар һәм илебез лексикографиясенең иң яхшы традицияләрен дәвам итеп, ТР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре коллективы татар теленең яңа фундаменталь аңлатмалы сүзлеген төзегән. Сүзлек үз эченә хәзерге заман татар әдәби теленең актуаль лексикасын һәм фразеологизмнарын, фәннең төрле өлкәләренә караган төшенчәләрне һәм атамаларны, аларның аңлатмаларын ала. Анда шулай ук татар теленең үзенең сүз ясалыш ысуллары хисабына барлыкка килгән неологизмнар да, тарихи сүзләр дә, әдәби телдә актив кулланыла торган алынма сүзләр дә урын алган. Сүзлектә 70 меңгә якын сүзгә һәм 10 мең фразеологик берәмлеккә аңлатма бирелә.

**Төп төшенчәләр**: лексикография, татар теле сүзлекләре, лексика, терминология, лексикология, аңлатмалы сүзлек

Бәяләмәдә Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге галимнәре төзегән «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»нә анализ ясала. Әлеге алты томлык фундаменталь хезмәт элек төзелгән аңлатмалы сүзлекләрдән үзенең күләме, эчтәлеге, тулылыгы, җентеклелеге һәм иллюстратив материалга бай булуы белән аерылып тора. 70 мең сүз һәм 10 мең фразеологик берәмлеккә аңлатма бирә торган алты томлык сүзлек хәзерге татар теле лексикасын төгәл һәм тулы чагылдыра торган гаять актуаль һәм кирәкле хезмәт ролен үти.

Лексиканың үзгәреп торуын, заманга бәйле рәвештә яңа төр берәмлекләр барлыкка килүен, булган лексемаларның яңа мәгънәләр яки мәгънә төсмерләре белән баюын, яңа сүзләр ясалуын, алынмалар кабул ителүен исәпкә алганда, 1977–1981 елларда дөнья күргән өчтомлык «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ннән соң, телдәге барлык үзгәрешләрне чагылдырган, яңа лексик берәмлекләрне теркәгән, бүгенге көн шартларына туры килерлек яңа аңлатмалар биргән мондый академик сүзлек бик кирәк иде.

Сүзлек Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге хезмәткәрләре тарафыннан профессор Ф. Ә. Ганиев җитәкчелегендә һәм ул әзерләгән инструкция нигезендә 2002 елда төзелә башлаган. Ул вакытта сүзлек дүрт томлык итеп кенә күзалланган, эш барышында күләме шактый арткан. Сүзлекнең аерым томнарын төзүгә бик күп авторларның өлеше кергән. Барлык томнарын да төзүдә катнашкан төп авторлар: Ф. И. Таһирова, И. И. Сабитова, Ф. Ф. Гаффарова, Г. Г.Саберова, Э. И.Сафина, О. Н. Галимова.

Сүзлекнең фәнни редакторлары: Ф. Ф. Гаффарова (I-III томнар), Г. Г. Саберова (I-II томнар), Ф. И. Таһирова (I-VI томнар), Р. Т.Сәфәров (III-VI томнар). I-V томнарның проект җитәкчесе – А. Ә. Тимерханов, VI томныкы – Р. Т. Сәфәров.

Сүзлекнең беренче томында «Сүз башы», «Файдаланылган махсус әдәбият һәм лексикографик чыганаклар исемлеге», «Сүзлектә файдаланылган башка чыганаклар турында мәгълүмат», «Сүзлектән файдаланучылар өчен белешмә» һәм «Шартлы кыскартылмалар исемлеге» китерелә. Тәфсилле, аңлаешлы итеп язылган мәгълүмат сүзлекләрнең алты томын да күзаллау өчен җирлек һәм алардан файдалану өчен уңайлы ярдәмлек булып тора.

Хезмәттә, беренче чиратта, урта мәктәп һәм югары уку йортлары дәреслекләрендә очраган төп төшенчәләрне белдергән сүзләр, лексик минимумнарда һәм терминологик сүзлекләрдә тәкъдим ителгән төп терминнар, дингә, халык ышануларына, мифологиягә, йолаларга, төрле ырымнарга бәйләнешле сүзләр, газета-журналларда урын алган иҗтимагый-сәяси терминнар, актив рәвештә яңадан кулланышка кереп бара торган искергән сүзләр, тарихи фактларны һәм электәге тормыш-көнкүрешне чагылдырган искергән сүзләр, әдәбиятта еш очраган һәм, киң кулланышка кереп, әдәби телне баетырдай дип табылган диалекталь сүзләргә һ.б. аңлатмалар бирелә. Ә фәннең һәм техниканың аерым тармакларында гына кулланыла торган үтә профессиональ сүзләр, әдәби телне баетмый торган җирле сөйләм сүзләре, жаргон сүзләр, хәрефләрдән һәм авазлардан торган кыскартылма сүзләр, ялгызлык исемнәре аңлатмалы сүзлеккә бөтенләй кертелмәгән.

Сүзлек берәмлеге итеп, барлык грамматик сүз төркемнәренә караган сүзләр дә алынган. Сүз төркемнәренә аңлатма биргәндә, төзүчеләр билгеле бер системаны сакларга тырышканнар. Мисал өчен, рәвешләр бер төрле, саннар икенче төрле аңлатыла, аларны аңлатуда эзлеклелек саклана һ.б. Конверсия юлы белән барлыкка килгән сүзләр һәм аларның мәгънәләре сүзлектә төп сүз мәкаләсендә күрсәтелә.

Вокабулалар арасында тамыр сүзләр генә түгел, төрле типтагы ясалма сүзләр дә очрый. Мисал өчен: кушымчалау юлы белән ясалган сүзләр (әшнәчелек, аһәңлелек, әйләнеш); саф кушма сүзләр (вольтметр, янбаш, башкисәр); кыскартылган кушма сүзләр (паровоз, рабфак); парлы сүзләр (аяк-кул, өзек-төтек, киемсалым); кушма һәм тезмә сүзләр (киек каз юлы, бала итәк) һ.б. Кушма сүзләрнең беренче яки икенче кисәкләре һәм аеруча продуктив алкушымчалар сүзлектә аерым мәкалә итеп бирелгән (мәсәлән, авиа-, авто-, агро-, -ара, био-, нео- һ.б.).

Зур коллективның күпьеллык җитди хезмәте булган бу сүзлек моңа кадәр дөнья күргән аңлатмалы сүзлекләрнең барлык уңай якларын исәпкә алып төзелгән. Телебезнең агглютинатив-аналитик тел булуын күздә

тотып, сүзлектә тезмә сүзләргә һәм тезмә фигыльләргә тиешле игътибар бирелгән. Лексемаларның мәгънәләре һәм мәгънә төсмерләре бик тәфсилле аңлатылган һәм матур әдәбияттан яки вакытлы матбугаттан мисаллар китерелгән. Лексемаларга стилистик һәм грамматик характеристика да хәзерге лексикография фәне казанышлары яссылыгында бирелгән.

Сүзлектә баш сүзләр алфавит тәртибендә китерелгән һәм баш сүздән соң аның сүз төркемен, чыганак телен, стилистик үзенчәлекләрен сыйфатлый торган билгеләре куелган. Үзләренә караган материал (аңлатмалар, мисаллар, фразеологик берәмлекләр) белән бергә алар сүзлек мәкаләсен тәшкил итә. Бер генә аңлатмалы вокабулалар да, 20-30 аңлатма китерелгән вокабулалар да очрый. Мисал өчен, бер аңлатмалы сүз:

**АШБА** *и. этн.* Алгы ягы сәйләннән, энҗе һәм тәңкәләр, асылташлар белән бизәлгән тасма яки такыясыман хатын-кыз баш киеме. *Зәңгәр күлдә яшел төнбоек, Чәчкәсеннән кашбау ишәрмен.* М. Җәлил. *Йөзекнең иң күркәме, ханшалар кия торган алтын кашбау кебек ялт-йолт килеп торганы Кәүсәрия Фатыйховнага насыйп булды.* Т. Галиуллин.

Берничә аңлатманы үз эченә алган сүзлек мәкаләсендә аңлатмалар бер-бер артлы яңа юлдан санап кителә:

**ДИСТӘ** *и. фар.* 1) Ун берәмлек; ун данәне эченә алган санау-хисаплау берәмлеге. *Әти-әниләреннән килгән бер дистәгә якын хат чыкты.* М. Гафури

2) *сөйл.* Ун еллык, ун елга тигез гомер. *Белем ягы да бик сай инде минем, яшем дә алты дистәнең өске ягына менеп бара.* Г. Бәширов.

3) Күп урынлы санда ахырдан икенче цифр исеме.

Билгеле булганча, телдә аеруча актив кулланыла торган сүзләрнең мәгънәләре һәм мәгънә төсмерләре генә түгел, әлеге сүз кергән фразеологизмнары, тотрыклы сүзтезмәләре дә күп була. Сүзнең барлык мәгънәләрен дә ачып бетергәннән соң, кызыл юлдан шул сүз белән башланган фразеологик берәмлекләр теркәлгән. Мисал өчен, *мөгез* сүзенең 9 мәгънәсе бар. Димәк, сүзлек мәкаләсе 9 аңлатмадан һәм аларның һәммәсенә туры килерлек иллюстратив материалдан гыйбарәт. Алардан соң *мөгез* сүзе белән бәйләнешле 5 фразеологизм китерелә. Ә тагын да киңрәк таралган *күз* сүзенең 22 мәгънәсенә аңлатма һәм *күз* сүзенә башланган 449 фразеологик берәмлек бирелгән. Әлеге аңлатмалар, мисаллар һәм телебезнең байлыгын, халкыбызның күзаллауларын, ышануларын үзенә туплаган тотрыклы берәмлекләр *күз* сүзе турында мөмкин булган кадәр тулы мәгълүмат бирә.

Башка сүзлекләрдән аермалы буларак, яңа аңлатмалы сүзлектә фигыльләргә игътибар зур. Фигыль сүз төркемнәрен аңлата торган сүзлек мәкаләләре киңлеге, тулылыгы белән игътибарны җәлеп итә. Татар телендә кулланыла торган фигыльләрнең искиткеч күпмәгънәле булуы һәм төрле очракларда кулланылуы сокландыра. Мисал өчен, *карау* фигыленең 17 мәгънәсе. Моннан тыш, *карап алу, карап бетерү, карап кую, карап тору, карап үтү, карап чыгу, карый башлау, карый бирү* һ.б. тезмә фигыльләр бирелә, һәрберсенә аңлатма һәм әдәби әсәрләрдән мисаллар китерелә. *Алу* фигыленең 54 мәгънәсе (шуңа өстәп, исем мәгънәсе функциясе, бәйлек функциясе, ярдәмче фигыль функциясендәге мәгънәләре), *төшү* фигыленең 64 мәгънәсе (шуңа өстәп, ярдәмче фигыль функциясендә тагын 6 мәгънә), 12 тезмә фигыле бар (*Төшә башлау* Акрынлап төшү; *Төшә язу* Чак кына төшми калу; *Төшеп китү* Кинәт, көтмәгәндә төшү һ.б.). Фигыльләрнең күпмәгънәле булуы һәм төрле формаларда актив кулланылуы телебезнең, сөйләмебезнең ни дәрәҗәдә бай булуын күрсәтә.

Алты томлыкта элеккеге сүзлекләрдә теркәлмәгән яңа вокабулалар бик күп. Алар арасында татар теленең үз җирлегендә ясалган сүзләр дә, чит телләрдән алынганнары да очрый. Мәсәлән, **АБ ЛХАНӘ** *и. гар.-фар. неол.* Рәсми урыннарда мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итү бүлмәсе; **АЛӘМХА** *и. неол.* Гонорар, авторлык акчасы; **Ү ТЕРӘР** *с. неол.* Үтә биек, бик күп катлы; **Ү ЗАЛЛЫ** *с. неол.* **1.** Мөстәкыйль, бәйсез. **2.** *рәв. мәгъ.* Мөстәкыйль, бәйсез рәвештә; **ХА ЛЫ** *с. неол.* Агрессив реклама сәбәпле бик нык популярлашкан, аеруча нык танылган; халык телендә булган; **ЕЛЕНД** *и. ингл. неол.* Блогерның үзе башкарган эш-гамәлне икенче берәүләргә кабатларга тәкъдим итүдән гыйбарәт Интернет ролигы жанры һ.б.

Сүзлекнең тагын бер игътибарга лаек ягы – әдәби телдә яки матур әдәбият телендә урын алган диалекталь, искергән, гади сөйләм сүзләренә һ.б. аңлатма бирү. Татар халкының

яшәеш һәм милли үзенчәлекләрен күрсәтә торган берәмлекләрнең барлык семантик төсмерләрен чагылдыру әлеге лексик катламның кулланылыш даирәсен киңәйтә (**ЯШЬЛӘВЕ** *и. диал.* Яшь үлән. *Ваһапов янында да Мостафаның үзен иркен тотуы, «браток»ның әледән-әле аның салпы ягына яшьләвек кыстыруы исенә төште.* Т. Галиуллин. *Арбасына яшьләвек чабып салган.* Мәйдан; **АТ Ы** *и. диал.* Чана артына озын бүрәнәләрне ташу өчен тагыла торган җайланма; **ЛА ШЫ** *с. диал.* Мускуллары, тәнендәге ите йомшарган, сәлперәйгән, тыгызлыгын югалткан. *Симез ат артык туйса, лапшык булыр.* Мәкаль. *Хатынның битләре лапшык, гәүдәләре бик тулы иде.* Ш. Камал).

Сүзләрнең орфографиясе гамәлдә булган традицион кагыйдәләргә нигезләнеп бирелгән. Басымны күрсәтү дә шул ук принципларны истә тотып башкарылган. Тезмә, кушма, парлы һ.б. сүзләрдә басымнар куелу татар телен өйрәнүчеләргә сүзләрне дөрес укырга ярдәм итә (*катлау-катлау, ярым-йорты, кыз урлау, ыйнак өмлә, кырлы-мырлы*). Сүзлектә басымы ахырга төшми торган башка сүзләрнең дә басымын күрсәтү очраклары бар (*иптәшлә́рчә, иренмичә, ярусл*ы һ.б.). Бу шулай ук кулланучыларга уңайлы булсын, сүзләрнең язылышында гына түгел, әйтелешендә дә хаталар китмәсен өчен эшләнгән.

Нәтиҗә ясап, шуны билгеләп үтәргә кирәк: алты томлык сүзлек лексик материалының, аңлатмаларының бай булуы һәм мәгълүматлылыгы белән аерылып тора. Татар теле лексикасын тулы күләмдә туплаган әлеге академик сүзлек төрле фән белгечләре, тәрҗемәчеләр, радио һәм телевидение, матбугат хезмәткәрләре, укытучылар һәм, гомумән, киң катлау укучылар өчен файдалы гамәли кулланма булып хезмәт итәчәк, татар телен дәүләт теле буларак өйрәнүдә, телне комплекслы тикшерүдә файдалы чыганак булачак.

---

# РЕЦЕНЗИЯ НА 6-ТОМНЫ «ТОЛ ОВЫ С ЛОВАРЬ ТАТАРС ОГО ЯЗЫ А» ( АЗА Н: ТӘҺСИ, 2015–2021)

**Альфия Шавкетовна Юсупова,**
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
alyusupova@yandex.ru.

В рецензии дана оценка шеститомному толковому словарю татарского языка («Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»; 2015–2021). Продолжая лучшие традиции татарской и отечественной лексикографии, коллектив ученых Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ составил новый фундаментальный толковый словарь татарского языка. Словарь включает актуальную лексику и фразеологизмы современного татарского литературного языка, термины и названия из различных областей науки и их толкования. В нем нашли место также неологизмы, образованные за счет собственных словообразовательных средств татарского языка, историзмы, заимствованные слова, активно употребляемые в общелитературном языке. В словаре около 70 тысяч слов и 10 тысяч фразеологических единиц.

**л ючевые слова:** лексикография, словари татарского языка, лексика, терминология, лексикология, толковый словарь